БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» 08 2025 ел № 232

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендәге торак пунктларның чикләрен билгеләү чараларын гамәлгә ашыру, терәк торак пунктның урам-юл челтәренә инвентаризация үткәрү һәм аның техник торышын бәяләү комиссиясе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый акт проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2025 елның 3 июнендәге «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Балтач шәһәр тибындагы поселогында урам-юл челтәренә инвентаризация үткәрү чараларын гамәлгә ашыру комиссиясен төзү турында» 172 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендәге торак пунктларның чикләрен билгеләү чараларын гамәлгә ашыру, терәк торак пунктның урам-юл челтәренә инвентаризация үткәрү һәм аның техник торышын бәяләү комиссиясе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 4.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.8. Җентекләп тикшерүне таләп итә торган аерым мәсьәләләр буенча эш төркемнәре төзелә.».

1.2. 4.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.9. Инвентаризация үткәрү нәтиҗәләре, комиссия карарларын нигезли торган мәгълүмат күрсәтелгән комиссия беркетмәсе белән 5 эш көне эчендә рәсмиләштерелә.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет - ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Ф.Хәйретдинов